Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXVII-9**

Балык Бистәсе штп.

2022 елның 29 октября

Җир салымы буенча салымнан азат итү турында

Россия Федерациясе Бюджет һәм Салым кодекслары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 30 нчы маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге җитештерү биналарының һәм индустриаль (сәнәгать) парк территорияләренең инфраструктурасын үстерү һәм төзекләндерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парк буларак Татарстан Республикасында дәүләт аккредитациясен алган кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм инфраструктурасы субъектларын сәнәгать мәйданчыклары буларак кулланыла торган җир кишәрлекләренә карата 2023 елга җир салымы буенча салымнан азат итәргә.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгы
урынбасары

Ф.Г. Әхмәтҗанова